КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 апрель г.Казань № 294

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VIII бүлекнең 9 пунктында:

икенче абзацта «җитәкче урынбасарларына билгеләргә» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VIII бүлекнең 10 пунктында:

икенче абзацта «җитәкче урынбасарларына билгеләргә» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен, «җитәкче урынбасарларын стимуллаштыру өчен» сүзләреннән соң «, баш хисапчы» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының расланган 2019 ел, 06 май, 380 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлектә:

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7.3 пункт өстәргә:

«7.3. Премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245-б номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын үтәгәндә спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең эш нәтиҗәлелеген арттыру максатларында бер тапкыр билгеләнә ала.»;

25 таблицаның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.13 пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.13. | Физкультура-спорт оешмасы инструкторы-методисты | икенче | 50»; |

VIII бүлекнең 9 пунктында:

икенче абзацта «җитәкче урынбасарларына билгеләргә» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен, «җитәкче урынбасарларын стимуллаштыру өчен» сүзләреннән соң «, баш хисапчы» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш хисапчыга» сүзләрен өстәргә.

3. Бу карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин